ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1611 2016 елның 24 ноябре

2016 елга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «71 нче номерлы күрү сәләте зәгыйфьләнгән балалар өчен компенсацияләүче башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучыларның туклануын оештыру бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «71 нче номерлы күрү сәләте зәгыйфьләнгән балалар өчен компенсацияләүче башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучыларның азык-төлек иминлеге һәм азык-төлек матдәләренә һәм энергиягә яшь физиологик ихтыяҗларына, рациональ һәм балансланган туклану принципларына туры килә торган туклануны оештыру максатларында, карар бирәм:

1. 2016 елның 1 сентябреннән расларга һәм гамәлгә кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «71 нче номерлы күрү сәләте зәгыйфьләнгән балалар өчен компенсацияләүче башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучыларның туклануын оештыру турында Нигезләмә;

1.2. 1-4 сыйныфлар өчен туклану бәясе 110 сум 00 тиен, шул исәптән җирле бюджет акчалары хисабына уку елы дәвамында бер укучыга 6 сум 50 тиен исәбеннән туклану бәясенең кыйммәтләнүенә өлешчә компенсация.

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Бюджет һәм финанслар департаментына (Логинова С.Н.) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «71 нче номерлы күрү сәләте зәгыйфьләнгән балалар өчен компенсацияләүче башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе өчен җирле бюджет ассигнованиеләре хисабына эшчәнлекне финанс ягыннан тәэмин итүгә каралган акчаларны үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә;

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р. Фәретдиновка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның 24 ноябрендәге
1611 номерлы карары белән расланган
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «71 нче номерлы күрү сәләте зәгыйфьләнгән балалар өчен компенсацияләүче башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучыларның туклануын оештыру турында Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «71 нче номерлы күрү сәләте зәгыйфьләнгән балалар өчен компенсацияләүче башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә (алга таба – Учреждение) белем алучыларның туклануын оештыру турында Нигезләмә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә, азык-төлек иминлеген һәм Учреждениедә укучыларның туклануын оештыру максатларында эшләнгән.

1.2. Учреждениедә укучыларны туклндыруны оештырудагы төп бурычлар булып тора:

- укучыларны азык-төлек матдәләренә һәм энергиягә яшь физиологик ихтыяҗларына, рациональ һәм баланслы туклану принципларына туры килә торган туклану белән тәэмин итү;
- туклануда кулланыла торган туклану һәм азык-төлек продуктларының гарантияләнгән сыйфаты һәм куркынычсызлыгы;
- сәламәт һәм яхшы сыйфатлы туклану принципларын пропагандалау.

1.3. Әлеге Нигезләмә билгели:

- Учреждениедә укучыларны туклндыруны оештыруның гомуми принциплары;
- 1-4 сыйныфларда туклануны оештыру тәртибе;
- түләүсез нигездә бирелә торган туклануны оештыру тәртибе.

## 2. Учреждениедә туклануны оештыруның гомуми принциплары

2.1. Мәктәп администрациясе укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүгә, сәламәт туклануның санитар-гигиеник нигезләрен һәм принципларын тәэмин итүгә, укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) белән консультация һәм аңлату эшләрен алып баруга юнәлтелгән оештыру-идарә карарларын кабул итүне тәэмин итә.

2.2. Укучыларны туклндыру муниципаль бюджет һәм ата-аналар акчасына оештырыла.

2.3. 1-4 сыйныф укучылары өчен дүрт тапкыр кайнар ризык (иртәнге, төшке, төштән соң, кичке аш) каралган.

2.4. Мәктәптә туклану белем бирү учреждениеләрендә 7-11 яшьлек балаларны тукландыруны оештыру өчен якынча ун көнлек меню нигезендә оештырыла. Расланган исемлекләрдә һәм менюда каралмаган продукцияне сату рөхсәт ителми.

2.5. Укучылар туклануында кулланыла торган азык-төлек чималының һәм азык-төлек продуктларының азык кыйммәтенең гигиеник күрсәткечләре «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПин 2.4.5409-08 Санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормативларга туры килергә тиеш.

2.6. Учреждениедә туклануны оештыруны туклануны оештыру өчен җаваплы баш пешекче (штат расписаниесе буенча) башкара.

2.7. Мәктәптә туклануны оештыру өчен гомуми белем бирү учреждениесе директоры җаваплы.

## 3. Учреждениедә туклануны оештыру тәртибе

3.1. Көн саен азык-төлек блогында һәм һәр сыйныфта учреждение директоры раслаган меню эленә, анда ризыкларның исемнәре, аларның күләме (граммнарда чыгу), бәясе күрсәтелә.

3.2. Учреждениедә азык-төлек блогы җитештерү эшчәнлеген тулы күләмдә башкара

5 көн – дүшәмбедән җомгага кадәр учреждениенең эш режимында.

3.3. Ризык кабул итү сәгатьләре учреждениенең директоры раслаган ризык кабул итү графигы нигезендә билгеләнә. Азык-төлек блогында туклану (төшке аш) сыйныфлар (төркемнәр) буенча башкарыла.

## 4. Түләүсез туклану тәртибе

4.1. Учреждениенең эш көннәрендә һәм сәгатьләрендә бушлай туклану хокукына ия:

- ятим балалар һәм опекага алынган балалар;
- инвалид балалар;
- Чернобыль АЭС авариясе нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы гаиләсе балалары;
- аларның җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган азкеремле, күпбалалы, тулы булмаган гаилә балалары;
- ата-ана хокукыннан мәхрүм итү; ата-ананы ирекътән мәхрүм итү (тикшерү астында булу вакытын да кертеп) белән бәйле рәвештә опека (попечительлек) рәсмиләштерелгән мәктәпкәчә яштәге балалар.

4.2. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында санап үтелгән укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру өчен Учреждениедә директор, педагогик коллективтан укучыларны тукландыруны оештыру өчен җаваплы һәм ата-аналар комитеты вәкилләре кергән комиссия төзелә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш.

4.3. Комиссия уку елы башында һәм алга таба да кирәк булганда:

- тапшырылган гаризаларны карый һәм укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карарлар кабул итә;

- азкеремле, тулы булмаган, күпбалалы гаиләләрне һәм аларның торак шартларын тикшерә, аларның матди хәлен, гаиләдәге балалар һәм иждивенецларның санын билгели, укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карар кабул итә, әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча тикшерү нәтиҗәләре белән беррәттән актта теркәп бара;

- категорияләр буенча өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучылар исемлеген раслый;

- бирелә торган төшке ашларның билгеләнгән тәртиптә расланган менюга туры килүен тикшерә.

4.4. Комиссия хокуклы:

- җитешсезлекләр белән әзерләнгән ризыкларны сатудан алырга;

- медицина хезмәткәре белән берлектә китерелә торган азык-төлек продуктларының туры килү-килмәвен тикшерә, үлчәүне тикшереп тора һ. б.

- тикшерү нәтиҗәләре буенча белем бирү оешмасы директорыннан җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрүне таләп итә.

4.5. Сыйныф җитәкчеләре, тәрбиячеләр:

- әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча түләүсез туклану алу өчен ата-аналардан яисә аларны алмаштыручы затлардан гаризалар кабул итәләр;

- гаризаларны алганнан соң өч көн эчендә комиссия каравына җибәрәләр;

- сыйныф укучыларының туклануын категорияләр буенча исәпкә алып баралар;

- укучылар һәм ата-аналар арасында укучыларны тулысынча туклану кирәклеге турында аңлату эшләре алып баралар.

4.6. Ата-аналар яки аларны алыштыручы затлар тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

4.7. Учреждение директоры:

- гаиләне тикшерү акты нигезендә категорияләр буенча укучыны түләүсез туклану белән тәэмин итүгә боерыклар чыгара;

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә категорияләр буенча укучылар исемлеген тәкъдим итә.

4.8. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, гомуми белем бирү оешмаларына барып, укучыларны тукландыруны оештыру, азык-төлек блогларында азык әзерләү технологиясен, чыгышын һәм санитар нормаларны үтәү мәсьәләләрен алып бара.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «71 нче номерлы күрү сәләте зәгыйфьләнгән балалар өчен компенсацияләүче башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучыларның туклануын оештыру турында Нигезләмәгә
1 нче кушымта

(Форма)

Түбән Кама шәһәре____________________МБГББУ ________сыйныф укучысы
Ф.И.А.ис. ________________________
гаиләсен тикшерү акты

Түбән Кама шәһәре __________20___ел

____________________________________________________________ гаиләсе
(социаль куркыныч хәлдә булган тулы булмаган, күпбалалы гаилә)
_____________________________________________________________________
(бүлмәләр саны, мәйданы, уңайлылыклар булуы, коммуналка, тулай торак, аренда )
_____________________________________________________________________
адресы буенча фатирда (йортта) яши.
Гаиләдә укучы балалар саны ___, гаиләдә эшләмәүчеләр саны _____.
Гаилә матди хәле _____________________________________________.
(яхшы, уртача, уртадан түбәнрәк)
Гаилә әгъзасына җыелма керем _____ сум тәшкил итә (ата-аналар гаризасы буенча).
Ата-аналарның эш урыны, башкарган вазыйфасы, уртача айлык хезмәт хакы:
_____________________________________________________________________.
Өстәмә мәгълүмат: __________________________________________
_____________________________________________________________________.
Гаиләнең торак шартларын һәм матди хәлен тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия карар кабул итә:
_______ сыйныф укучысы ___________________________________
(Ф. И. О.)
өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ (мохтаҗ түгел).
(кирәгенә сызарга)

Комиссия рәисе: ___________________________ _______________________
(имза, дата) (Ф. И. А. ис.)
Комиссия әгъзалары: _________________________ __ ______________________
(имза, дата) (Ф. И. А.ис.)
Сыйныф җитәкчесе: ___________________________ _______________________
(имза, дата) (Ф. И. А.ис.)

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «71 нче номерлы күрү сәләте зәгыйфьләнгән балалар өчен компенсацияләүче башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучыларның туклануын оештыру турында Нигезләмәгә

2 нче кушымта

(Форма)

Түбән Кама шәһәре___ мәктәбе укучыларының туклануын оештыру буенча комиссиягә
_______________________________________

(мөрәҗәгать итүче Ф. И. А.ис.)
___________________________________
(адресы)

гариза.

Минем улым (кызым, опекага алынучы) ________________________________
_____________________________________________________________________________
(Ф. И. А. ис.)
__________ сыйныф укучысын түләүсез туклану белән тәэмин итүегезне сорыйм.
Гаилә әгъзасына җан башына уртача керем ___________________ сум тәшкил итә
Өстәмә рәвештә хәбәр итәм: ______________________________________________
_____________________________________________________________________________.
Гаилә кеременең күләмен раслаучы документларны кушып бирәм.

____________________
(Дата, имза)

--------------------------------

Гаризага кушымта итеп бирелә:

1. Йорт идарәсеннән гаилә составы турында белешмә.
2. Эш урыныннан хезмәт хакы турында белешмә (соңгы 6 айда).
3. Пенсия, пособиеләр күләме турында белешмә.
4. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгеннән белешмә (эшләмәүчеләр өчен).
5. Күпбалалы гаилә турында таныклык күчермәсе (булганда).

6. Опека һәм попечительлек бүлегеннән белешмә, яисә балигъ булмаганнарны опекага алу турында күрсәтмә күчермәсе.

7. Инвалид балалар өчен МСЭ медицина белешмәсе күчермәсе.

8. Өйләнешү яки аерылышу турында таныклык күчермәсе.

9. Алиментлар алу турында белешмә (булганда).

10. Чернобыль АЭС авариясе нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгының күчермәсе.